**Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында**
**2021 елның 9 аенда гражданнар мөрәҗәгате белән эшләү турында мәгълүмат**

2021 елның 9 аенда Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында гражданнардан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүләрдә алынган **6824** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2020 елда – 6606).

Барлык мөрәҗәгатьләрнең 4**158** е – язмача кергән мөрәҗәгатьләр (2020 елда – 4595).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 6001 кешедән 203 коллектив мөрәҗәгать керде (2020 елда – 6458 кешедән 173 коллектив мөрәҗәгать).

Шәһәр халкын борчыган мәсьәләләрнең уңай хәл ителүе өчен 33 мөрәҗәгать аша шәһәр Хакименә һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә рәхмәт сүзләре җиткерелгән.

4158 мөрәҗәгатьнең 752се уңай хәл ителде, бу гомуми санның 18,1%ын тәшкил итә, 133 мөрәҗәгать ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды; калганнары буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәтүче гражданнарның составы түбәндәге категорияләр белән күрсәтелә:

- пенсионерлар: 288 (6,93 %);
- эшләүчеләр: 178 (4,28 %);
- эшсезләр: 62 (1,49 %);
- эшмәкәрләр: 46 (1,11 %);
- хезмәткәрләр: 44 (1,06 %);
- хуҗабикәләр: 42 (1,01 %);
- интеллигенция: 21 (0,51 %);
- укучылар: 18 (0,43 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 3459 (83,19 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең ташламалы категориягә ия булуын күрсәтүчеләрнең күпчелеген инвалидлар – 140 (3,37 %), күп балалы гаиләләр – 111 (2,26 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – 19 (0,46 %), ялгыз ата-аналар – 11 (0,26 %), Бөек Ватан сугышы ветераннары – 4 (0,10 %) тәшкил итә.

Гражданнардан язмача алынган мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, 2021 елның 9 аенда шәһәр халкы өчен түбәндәге мәсьәләләр актуальрәк булып саналган:

- торак-коммуналь хуҗалык – 1430 (2020 – 1322);
- төзелеш – 418 (2020 – 334);
- юл хуҗалыгы – 348 (2020 – 431);
- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия – 336 (2020 – 466);
- җирдән файдалану – 305 (2020 – 269);
- торак өлкәсе – 267 (2020 – 303);
- социаль тәэмин итү – 204 (2020 – 347);
- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 152 (2020 – 166);
- сәламәтлек саклау – 148 (2020 – 157);
- транспорт хезмәте күрсәтү – 133 (2020 – 162);
- законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 91 (2020 – 163);
- финанс өлкәсе – 81 (2020 – 77);
- хезмәт һәм мәшгульлек –51 (2020 – 123);
- элемтә мәсьәләләре –47 (2020 – 56);
- төрле характердагы мәсьәләләр – 147 (2020 – 219).

**2666** чаллылы шәхси кабул итүдә булды (2020 – 2011).

958 мөрәҗәгать буенча кирәкле чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән 1661 гражданга аңлатмалар бирелде, 47 мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 256 чаллылы турыдан-туры кабул ителде.

Җирле үзидарә органнарында гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы һәр көнне уздырыла, аларны үз вакытында карауга контрольлек гамәлгә ашырыла, башкару дисциплинасы анализлана.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Һәр мөрәҗәгать итүчегә гамәлдәге законнар нигезендә язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелә.